Татарстан Республикасы Зәй  муниципаль районы гомуми белем учреждениесенең «Мансур Хәсән улы Хәсәнов исемендәге Бигеш урта гомуми белем мәктәбе»

Номинация “Листая страницы истории школы” (эссе) / “Мәктәбемнең тарихи битләрен  караганда”(эссе)

Тема: “Кто любит свое Отечество, то подает лучший пример любви к человечеству” (А.В.Суворов)

“Кем  Ватанын ярата,  шул кешелекне яратуның иң яхшы үрнәген күрсәтә” (А.В.Суворов)

Юсупова Әдилә Сәгыйрь кызы, 6нчы сыйныф

Юсупова Гөлнур Фаил кызы, татар теле һәм әдәбияты укытучысы

Бигеш, 2020 ел

Буыннардан буыннарга тапшыра алган
Сүндермичә милләт учагын.
Бүген дә әнә ялкынланып яна,
Киләчәккә балкыш булып нуры бара
Бигеш мәктәбемнең белем учагы!
(Нөзелә Хабибуллина)

Кешенең туган җире, тәүге адымнар ясаган һәм дөньяны танып белүдә беренче мәгълүматларны биргән тирәлеге аның хәтерендә мәңге онытылмаслык хатирәләр булып сакланып кала. Безнең Бигеш төбәген, аның халкын укымышлы, гыйлемле як, дип йөртәләр. Бу сүзләрне мин еш кына әти-әнидән, мәктәптә, башка җирләрдә дә кешеләр үзара сөйләшкәндә ишеткәнем бар. Нәрсәдә чагыла аның гыйлемлеге? Чыннан да, авылның тарихын өйрәнүчеләрнең истәлекләрен тыңласаң, аларда мәдәни һәм мәгариф үсешенең тирә-як авылларга караганда күпмедер дәрәҗәдә алданрак барганын тоемлыйсың. Мәчетләр дә, мәдрәсә-мәктәпләр дә безнең Бигештә бу эшне эшләргә мөмкинлек булу белән барлыкка килгәннр. Рәсми төстә белем бирү системасы оешуга да берничә елдан 125 ел тулды. Инде тормышыбызның Совет чоры дип аталган өлешен генә алып өйрәнә башласаң да, Бигеш төбәгендә туып, аның мәктәбендә белем алган шәхесләрнең күплегенә ис китәрлек. Алар арасында нинди генә профессия кешеләре юк: укытучы, врач, самолет төзүче, галим – агроном, галим – инженер, фән эшлеклеләре, сәнгать кешеләре, спортсменнар ... җыеп әйткәндә матди һәм рухи байлык. Минем аларның берничәсен генә санап китәсем килә: Низамов Равил Афзал улы - педагогика фәннәре кандидаты, Биктаһиров Раиф Терентий улы - юридик фәннәр кандидаты, МГУ укытучысы, Гайсин Илшат Әхәт улы - академик, авыл хуҗалыгы фәннәре докторы, Гыйльмуллин Мансур Файзрахман улы - математика фәннәре кандидаты, Алабуга педагогия университеты галиме, Ахунҗанов Галимҗан Хакимҗан улы - фиология фәннәре докторы, Ханнанов Рәшит Габдрахман улы - чаңгы буенча РСФСР чемпионы, Ситдикова Гөлнур Фахразый кызы -

җиңел атлетика буенча РСФСР чемпионы. Ә инде  тарих фәннәре докторы, археолог, профессор  Хуҗин Фаяз Шәрип улының хезмәтләре турында Татарстан гына түгел, бөтен Рәсәй, дөнья, фән әһелләре хәбәрдар. Ул данлыклы Казаныбызның 1000 еллыгын да исбат иткән галимнәребезнең берсе булуы белән без горурланабыз. Шулар арасында XX гасырның күренекле галиме, Татарстанда фәннең үсешенә, туган телебезне саклауга тиңсез өлеш керткән шәхес, академик Мансур абый Хәсән улы Хәсәнов турында аерым әйтеп китми булмый. Безнең мәктәп аның исемен йөртә. Әйе, “Агач – җимеше белән, кеше – эше белән” диелгән татар халык мәкалендә. Бу мәкаль санап кителгән кешеләргә бик туры килә. Алар чынлап та, үзләренең эшләре белән горурланырлык эз калдырдылар. Авылыбызда туып, мәктәптә белем алып, югары хезмәт урыннарына ирешкән якташларыбыз арасында бик күп күренекле шәхесләребез булуына карамастан, мәктәпкә Мансур абый исеме бирелүе юкка гына түгелдер. Моның серен беләсе килеп, өлкәннәргә мөрәҗәгать иттем. Аларны, өлкәннәрне,  тыңласаң, синең исемең белән нәрсәне дә булса аталуын телисең икән, бары тик Мансур абый кебек халкыңа хезмәт итү кирәк икәннен аңлыйсың.

Әдәбият галиме, академик, җәмәгать һәм дәүләт эшлеклесе Мансур Хәсән улы Хәсәнов 1930 елның 25 июнендә Татарстанның Тукай районы Бигеш авылында крәстиян гаиләсендә туа. Җидееллык мәктәпне һәм 1948 елда Алабуга шәһәрендә китапханә техникумын тәмамлаганнан соң, туган якларында ике ел уку йорты мөдире булып эшли. 1950–1955 елларда ул – Казан дәүләт университеты студенты. Университетның татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлагач, аны әдәбият кафедрасы каршындагы аспирантурада укырга калдыралар. Аспирантураны тәмамлагач, 1958–1961 елларда «Татарстан яшьләре» газетасының баш мөхәррире, университетта ассистент, тарих-филология факультетының декан урынбасары хезмәтендә була. 1961–1971 елларда КПССның Татарстан өлкә комитеты аппаратында лектор, мәдәният бүлеге мөдире, идеология бүлеге мөдире урынбасары һәм җиде ел фән һәм уку йортлары бүлеге мөдире булып эшли. 1971–1983

елларда М.Хәсәнов – Татарстан Министрлар Советы Рәисе урынбасары, ә 1984–1989 елларда Министрлар Советы Рәисенең беренче урынбасары хезмәтендә. Шул чорда күп тапкырлар Татарстан Югары Советына депутат итеп сайлана. 1961 елда – кандидатлык, 1971 елда докторлык диссертациясен яклый. 1991 елның ахырында республикада Россиядән аерым мөстәкыйль Фәннәр академиясе оеша, 1992 елның башында исә бу гыйльми оешма әгъзалыгына сайлаулар уздырылып, аның беренче президенты итеп Мансур Хәсәнов сайлана, 1997 һәм 2002 еллардагы икенче һәм өченче тапкыр сайлаулар вакытында да президентлык вазифаларын башкара. Бу вазифаларын ул 2006 елның башына кадәр дәвам иттерә. Президентлык вазифаларыннан тыш ул Татар энциклопедиясе институтының директоры булып та эшли.

Академик Мансур Хәсәнов гуманитар фәннәр өлкәсендә үз гыйльми мәктәбен булдырган күпкырлы талант иясе дә. Үзенең күптөрле һәм күп юнәлешле җитәкчелек вазифаларын М.Хәсәнов әдәбият фәне һәм әдәби тәнкыйть өлкәсендәге иҗади эшләре белән бергә бәйләп алып бара.

М.Хәсәнов егерме җиде ел буена Татарстан Югары Советы депутаты була, озак еллар дәвамында Югары Советның Мәгариф, фән һәм мәдәният комиссиясен җитәкли, 1971–1992 елларда әдәбият-сәнгать өлкәсендә Г.Тукай исемендәге Дәүләт премияләре комитетына җитәкчелек итә, 1993 елдан башлап Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Фән һәм техника буенча Дәүләт премияләре комиссиясе рәисе вазифаларын башкара

М.Хәсәнов дәүләт эшендә һәм иҗтимагый-сәяси, фәнни тармакларда ирешкән казанышлары өчен ике тапкыр Хезмәт Кызыл Байрагы ордены (1966, 1986), «Мактау Билгесе» ордены (1971), Халыклар Дуслыгы ордены (1980) һәм IV дәрәҗә «Ватан алдындагы хезмәтләре өчен» ордены (2000) белән бүләкләнә. Ул – Кол Гали исемендәге Халыкара премия лауреаты (1994), 1995 елда аңа «Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе» дигән шәрәфле исем бирелә, Россия Гуманитар фәннәр

академиясенең хакыйкый әгъзасы (1995). Галим 2005 елда «Татарстан Республикасы каршындагы казанышлары өчен» орденына лаек булла.

Мансур абый сугышның соңгы елларында Бигештә 7нче сыйныфны тәмамлаганнан соң, алга таба белем эстәү теләге белән авылдан чыгып китә. Әмма аның күңеле авылда кала. Ул авыл халкының белемле булуы хыялы белән яна. Дөнья күләмендә ачышларның, яңа җитештерү технологияләренең авыл халкына үтеп керүен тизләтергә омтыла. Татарстан Министрлар Советында эшләгән чорында да, аңа хәтле партия өлкә комитетында эшләгән дәвердә дә, ул авылга кайткач, мәктәп, авыл җитәкчеләре белән очраша. Авылның үсешен тәэмин итү юлында туган проблемаларны хәл итү ысулларын җитәкчеләргә аңлата. Инде катлаулы мәсьәләләр туганда, ул турыдан-туры үзенең эш урыны дәрәҗәсеннән торып катнаша иде, дип искә алалар аның турында. Бигештә, Татарстан авыллары арасында беренчеләрдән булып, көн таләпләренә җавап бирә алырлык мәктәп бинасы, аның ян корылмалары һәм спорт залы үсеп чыга. Күрше авыллардан йөреп укучы балалар өчен интернат торак йорт төзелә. Урта мәктәп XX гасыр азагында урта белем бирү уку йортларында шул чор өчен иң алдынгы уку әсбаплары белән җиһазландырыла. Хезмәт тәрбиясе бирү класс - кабинетында егетләрне механизатор белгечлегенең иң катлаулы серләренә төшенерлек җиһазлар монтажлана. Мәктәп тормышында туган күп төрле башка проблемалар да Мансур абыйның кайгыртучанлыгыннан читтә калмыйлар. Мәктәп белән бергә авыл тормышындагы уңай үзгәрешләрнең һәркайсында Мансур абыйның теге яки бу дәрәҗәдә катнашы бар икән. Чаллы – Зәй төбәгендә беренчеләрдән төзелгән мәдәният йорты, әле үткән гасырның 70нче елларында ук авылның Чаллы – Әлмәт автомобиль трассасына асфальт юл белән тоташуы, төбәктә төзелгән күперләр һәм башка, кешеләргә хезмәт күрсәтү оешмалары барлыкка килүе һәм аларның бүген дә эшләп торуы, шулай ук үз вакытында Мансур абый Хәсән улының авыл һәм аның халкы турында кайгыртуы, борчылуы нәтиҗәсе дип кабул ителә.

“Ул бу санап кителгән эшчәнлекне үзенең төп эшенә зарар китермичә, Татарстан халкы алдындагы бурычын үтәү барышында башкара. Мансур абый гомеренең соңгы көннәренә кадәр татар милләтенә турылыклы калды, милли аңның, мәдәниятнең, фәннең үсүенә хезмәт итте. Татарстанны, аның халкын, татар телен алдынгы итеп күрергә теләде. Шуның өчен көчен дә, сәламәтлеген дә кызганмады. Туган як авылында үзе укыган мәктәптә аның исеменең мәңгеләштерелүе табигый күренеш, дип исәплим,”- дип сөйләде миңа лаеклы ялдагы тарих укытучыбыз Рәүф Гатуф улы Насыйбуллин.

Мин мәктәбемнең, чыннан да, бай тарихлы булуына ышандым. Кешелек дөньясы алга бара, дөньяга караш та үзгәрә, материаль һәм рухи кыйммәтләр дә яңара. Тормыш ничек кенә үзгәрмәсен, яшәеш ни дәрәҗәдә үсеш алмасын, әмма бары тик белемгә ия булган кеше генә, чын мәгънәсендә, бу дөньда үзен иреклe хис итә ала. “Тарихны фаразлау аз, аны исбатларга кирәк, галимнең, эзләнүченең максаты шундый булырга тиеш”,- дип язылган безнең мәктәптәге бер стендта. Бу - Мансур абыйның сүзләре. Тормыш бездән, яшь буыннан, чыннан да исемеңне мәңгеләштерүне телисең икән, Мансур абый кебек халкыңа хезмәт итүне таләп итә. Безнең буын моңа әзер!

Эшемне безнең мәктәбебезне тәмамлаган якташыбыз Нөзелә апа Хабибуллинаның шигъри юллары белән башлаган идем, ә азагын үземнең сүзләрем белән тәмамлыйсым килә.

Безнең мәктәп - гыйлем йорты-
Авылым уртасында.
Зур шәхесләр укыган монда,
Күп еллар дәвамында.
Мансур Хәсәнов исеме бирелде,
Безнең мәктәбебезгә.
Тырышып белем алырбыз,
Үрнәк булырбыз без дә.